ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) өченче абзацта «Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм терроричылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«терроричылыкны финанслауга каршы тору функцияләрен гамәлгә ашыручы ведомствоара координация органы тарафыннан «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм терроричылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль законның $7^4$ статьясы нигезендә акчаларыннан яисә башка мөлкәтеннән файдалануын туктатып тору (туктату) турында карар чыгарылган оешма яисә физик зат.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 07 март
№ 5-ТРЗ